| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН<br>ГЛАВА ТЮРНЯСЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ТӨРНӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Төрнәс ав. **КАРАР**

« 13 » октябрь 2025 ел № 1

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 25 октябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авылы Кызыл Армия урамы 25нче йорт адресы буенча урнашкан ФАП янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылының Көнчыгыш, Юл буе, Кызыл Армия, Кутузов, Суворов, Ворошилов, Көнбатыш, Совет, Көнбатыш тыкрыгы, Совет тыкрыгындагы йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2025 елның 25 октябрендә 12 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авылы Яшьләр урамы буенча 6нчы йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге Төрнәс авылының Яшьләр, Кыр урамнарындагы йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Төрнәс авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.
4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Төрнәс авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.
5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда 1 гр инвалидлардан тыш., балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, СВО катнашучылары һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш Төрнәс авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, алынган акчаларны

түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Төрнәс торак пунктында урамнарны яктырту җайланмасы;
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Төрнәс т. п. юлларын салу, сезонлы карап тоту);
- Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм чишмәләрдән су алуны тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау Төрнәс торак пунктында су белән тәэмин итү, аны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү (скважиналарны лицензияләү);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү ( янгын гидрантлары);
- Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү (трактор өчен запас частьләр сатып алу, урамнарда агачлар җыештыру, авыл урамнарын төзекләндерү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Төрнәс авыл җирлегенең Төрнәс авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Төрнәс авыл җирлеге башлыгы С.В. Белов